**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Түйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Түйкә авылы №121-55 13 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Түйкә авыл җирлеге Советы 2014 елның 21 ноябрендәге
105 номерлы “Физик затларның милкенә салым» карарына
өстәлмәләрне кертү хакында (20.08.2015 № 131, 28.10.2015 №13-3,
24.04.2018 № 97-44 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 статьясындагы 2 пункты һәм 406 статьясындагы 1 пункты нигезендә,

Түйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советы 2014 елның 21 ноябрендәге 105 номерлы “Физик затларның милкенә салым» карарына (20.08.2015 № 131, 28.10.2015 №13-3, 24.04.2018 № 97-44 карарлар редакциясендә) түбәндәге өстәлмәләрне кертергә:

1.1. 3.3 пунктта:
а) 2 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзацны өстәргә:
«фатир өлешләре»;
б) 3 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге бишенче абзацны өстәргә:
"торак йортлар өлешләре".

2. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта - «Маяк» газетасында үз көченә керә һәм физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле рәвештә 2017 елның 01.01.2017 елдан башлап хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р. Закирова